**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү мәсьәләләре буенча даими эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турында» 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-445 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-211 номерлы, 2010 елның 18 августындагы ПУ-536 номерлы, 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы, 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2013 елның 6 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-305 номерлы, 2015 елның 7 октябрендәге ПУ-973 номерлы, 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы һәм 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү мәсьәләләре буенча даими эш төркеме составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) эш төркеме составыннан А.А. Здуновны чыгарырга;

б) эш төркеме составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 27 ноябрь
№ ПУ-805